**I вариант**

**Эш башкару өчен күрсәтмә**

Татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныфын тәмамлаучыларга татар теленнән бердәм республика тестын үтәү өчен, 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә. Тест биремнәре 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек** 1 биремнән гыйбарәт. 2 тапкыр тыңланган текстның кыскача эчтәлеге (изложение) 2 нче номерлы бланкка языла.

**Икенче бүлек** укучылар үзләре укыган текст нигезендә эшләнелә. Ул 9 биремнән (2-10) тора.

2 – 3 нче биремнәрне үтәгәндә, дөрес җавапны тәкъдим ителгән 4 варианттан сайлап алып, 1 нче номерлы җавап бланкына 1 цифр белән язарга кирәк.

4-10 нчы биремнәргә җавапларны мөстәкыйль рәвештә формалаштырасыз. Әлеге биремнәргә җаваплар сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән 1 нче номерлы җавап бланкына языла. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга кирәк.

**Өченче бүлектәге биремнәрне** эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән ике биремнең (11.1 яки 11.2) берсен генә сайлап алыгыз һәм дәлилле киңәйтелгән җавап языгыз. Әлеге бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Бердәм республика тесты материалларының барлык бүлекләрендәге биремнәрне үтәгәндә, орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне үтәгәндә, карамаладан файдаланырга ярый. **Шуны истә тотыгыз**: карамаладагы язмаларыгыз эшне бәяләгәндә исәпкә алынмаячак.

Биремнәрне эзлекле рәвештә башкару тәкъдим ителә.

Балларны бергә кушканнан соң, гомуми балл чыгарыла. Шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

**Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне эшләгез.**
**Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.**

**1.Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.**

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложение күләме **50 сүздән** ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**2 нче бүлек**

**Текстны укыгыз һәм 2-10 нчы биремнәрне үтәгез.**

**Болын чәчәкләре**

1) Мин шәһәрдә туып үстем. 2) Ләкин һәр җәйне мине авылга, әбиләремә кайтаралар иде. 3) Ул кайтуларны әкият дөньясына кайткандай көтеп ала идем.

4) Мин авылга кайтуга, аякларымнан кыйммәтле шәһәр түфлиләрен салып ташлыйм да болынга йөгерәм. 5) Беркемнән дә курыкмыйча, оялмыйча, әдәп кагыйдәләренең дөньяда барлыгын да онытып, мин болынга йөгерәм. 6) Андагы чәчәкләр минем билемә җитәләр, алардан килгән әллә нинди тәмле исләр елыйсымны китерәләр. 7) Мин инде бу

кадәр могҗиза, матурлыкка түзә алмый күзләремне йомам да болын чәчәкләре өстенә авам. 8) Чәчәкләр, иелеп-иелеп, битләремнән, күзләремнән үбеп алалар, муенымны кытыклыйлар. 9) Мин аларны өзмим, өзгәч, алар шунда ук шиңәләр, ямьсезләнәләр. 10) Мин аларны беркайчан да өзмәячәкмен. 11) Миңа гел шулай җәй булыр, гел шулай болын һәм чәчәкләр булыр кебек.

12) Ә беркөнне, бирегә йөгереп килгәч, мин чәчәкләремне тапмадым. 13) Болыным да үзгәреп, боегып калган. 14) Чәчәкләр, бер рәт булып, җиргә ауганнар, төпләре шыксызланып тырпаешып торалар. 15) Аякларым чәнчеп авыртуданмы, болынымның рәхимсез талануыннан әрнепме, елый-елый, печән чабучы ирләр янына йөгерәм.

16) – Ник тиясез сез ул чәчәкләргә?- дип кычкырам мин килә-килешкә.

17) Аларның җавапларын тыңлап тормыйча, чабылган болын буйлап авыл ягына йөгерәм.

18) – Әби, нигә ул чәчәкләргә тияләр, ник болынны ямьсезлиләр?

19) – Соң вакыты җиткәч, чәчәкләрне дә чабалар инде, балам. 20) Чәчәк дип, үлән бит инде ул, кышын малларны ач тотып булмый бит.

21) Мин тагын тузан туздырып авыл буенча йөгереп узам. 22) Кая барасымны үзем дә белмим, хәзер инде барып капланырга болын да юк. 23) Болында барысы да ду килеп утын-печән әзерли. 24) Аларга бу кыңгырау чәчәкләре – печән, менә бу ак каенкаем, мескен каенкаем – утын.

25) Икенче җәйдә мин инде болынның чабылачагын алдан ук белә идем. 26) Өченче җәйдә мин инде аның чабылырга тиешлеген аңладым. 27) Калган җәйләрдә мин инде беркайчан да тилереп-кыргыйланып, ул болынга йөгермәдем. 28) Барсам да, тыныч кына, ял итәргә генә бара идем. 29) Минем балачак хыялларымны шулай үткен чалгы белән бер селтәнүдә юк итә алсалар да, матурлыкка табынган җанымны сындыра алмадылар. 31) Мин ул чәчәкләрне беркайчан да өзмәдем...

(Фәүзия Бәйрәмовадан*)

***Фәүзия Бәйрәмова** (Фәүзия Әүхәди кызы Бәйрәмова) (1950 елда туган)- татар халкының күренекле сәясәтчесе, җәмәгать эшлеклесе. “Болын”, “Соңгы намаз” әсәрләре укучыларга яхшы таныш.

**2-10 нчы биремнәрнең җавапларын сүз, (сүзтезмә) яки цифр белән күрсәтегез.**

2.**Ирен гармониясенә буйсынмаган** сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез:

1) Беркемнән дә курыкмыйча, оялмыйча, әдәп кагыйдәләренең дөньяда барлыгын да онытып, мин болынга йөгерәм.

2) Икенче җәйдә мин инде болынның чабылачагын алдан ук белә идем.

3) Өченче җәйдә мин инде аның чабылырга тиешлеген аңладым.

4) Чәчәкләр, иелеп-иелеп, битләремнән, күзләремнән үбеп алалар, муенымны кытыклыйлар.

3.Сөйләмнең сәнгатьлелеген арттыру максатыннан, **фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез:

1) -Чәчәк дип, үлән бит инде ул, кышын малларны ач тотып булмый бит.

2) Болыным да үзгәреп, боегып калган.

3) Ә беркөнне, бирегә йөгереп килгәч, мин чәчәкләремне тапмадым.

4) Болында барысы да ду килеп утын-печән әзерли.

4. 16-20 нче җөмләләрдән **үткән заман сыйфат** фигыльне күчереп языгыз.

5. 25-28 нче җөмләләрдән **юклык алмашлыгын** табып языгыз.

6. 5 нче җөмләдән *әхлак* сүзенең **синонимын** табып языгыз.

7. 25 нче җөмләнең **грамматик нигезен** күчереп языгыз.

8. 21-23 нче җөмләләрдән **теркәгечсез тезмә кушма җөмләнең** номерын языгыз?

9. Җөмләдә барлык тыныш билгеләре номерланган. **Тиңдәш кисәкләр** янында куелган **тыныш билгесенең** номерын языгыз.

Аларга бу кыңгырау чәчәкләре –(1) печән,(2) менә бу ак каенкаем,(3) мескен каенкаем –(4) утын.(5)

10.Сөйләмнең тәэсир итү көчен арттыру өчен, 14-17 нче җөмләләрнең берсендә **кире сүз тәртибе** кулланылган. Шул җөмләнең номерын языгыз?

## 3 нче бүлек

**2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 11.1 һәм 11.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып үтәгез. Яза башлар алдыннан, сайланган биремнең номерын күрсәтегез.**

11.1. **“Минем балачак хыялларымны шулай үткен чалгы белән бер селтәнүдә юк итә алсалар да, матурлыкка табынган җанымны сындыра алмадылар. Мин ул чәчәкләрне беркайчан да өзмәдем... ”** җөмләләрендә әйтелгән фикерләрне сез ничек аңлыйсыз? Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш. Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз. Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый. Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен, ноль балл куела.

11.2**. “Дөньяны матурлык коткарыр”,- дигән бер акыл иясе. Бу җөмләнең** мәгънәсен ничек аңлыйсыз? **“Күңел матурлыгы”** төшенчәсенә аңлатма бирегез. **“Дөньяны матурлык коткарыр”** дигән темага сочинение языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш. Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый. Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен, ноль балл куела.

**II вариант**

**Эш башкару өчен күрсәтмә**

Татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныфын тәмамлаучыларга татар теленнән бердәм республика тестын үтәү өчен, 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә. Тест биремнәре 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек** 1 биремнән гыйбарәт. 2 тапкыр тыңланган текстның кыскача эчтәлеге (изложение) 2 нче номерлы бланкка языла.

**Икенче бүлек** укучылар үзләре укыган текст нигезендә эшләнелә. Ул 9 биремнән (2-10) тора.

2 – 3 нче биремнәрне үтәгәндә, дөрес җавапны тәкъдим ителгән 4 варианттан сайлап алып, 1 нче номерлы җавап бланкына 1 цифр белән язарга кирәк.

4-10 нчы биремнәргә җавапларны мөстәкыйль рәвештә формалаштырасыз. Әлеге биремнәргә җаваплар сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән 1 нче номерлы җавап бланкына языла. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга кирәк.

**Өченче бүлектәге биремнәрне** эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән ике биремнең (11.1 яки 11.2) берсен генә сайлап алыгыз һәм дәлилле киңәйтелгән җавап языгыз. Әлеге бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Бердәм республика тесты материалларының барлык бүлекләрендәге биремнәрне үтәгәндә, орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне үтәгәндә, карамаладан файдаланырга ярый. **Шуны истә тотыгыз**: карамаладагы язмаларыгыз эшне бәяләгәндә исәпкә алынмаячак.

Биремнәрне эзлекле рәвештә башкару тәкъдим ителә.

Балларны бергә кушканнан соң, гомуми балл чыгарыла. Шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

## 1 нче бүлек

**Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне эшләгез.**
**Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.**

**1.Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.**

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложение күләме **50 сүздән** ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## 2 нче бүлек

**Текстны укыгыз һәм 2-10 нчы биремнәрне үтәгез.**

### Кыйммәтле эш

1) Шамил чыгып китәм дигәндә генә, аягы нindидер бер йомшак төенгә кагылып китте. 2) Караса, кулъяулыгына төрелгән бер нәрсә ята! 3) Кемдер ялгыш төшереп калдырган, күрәсең. 4) Малай, төенне кулына алып, чишеп карады. 5) Акча! 6) Берәрсенең сумкасыннан төшеп калгандыр инде бу. 7) Менә хәзер иясе йөгереп килеп җитәр.

8) Шамил, адымнарын тизләтеп, өйгә таба атлады. 9) Әнисе дә кайтып җитәр, озакламый әтисе дә. 10) Менә бергәләп аш өстәле тирәсенә утырырлар. 11) Ә Шамилнең кесәсендә – акча. 12) Әтисе дә, әнисе дә ул акча турында бернәрсә дә белми. 13) Алар, Шамилнең бүген нинди билгеләр алып кайтуы турында сораша-сораша, гөрләшеп чәй

эчеп утырырлар. 14) Ә кесәдә чит кешенең акчасы, табылган акча, кыштырдап, һаман Шамилнең күңелен кытыклап торыр...

15) Тукта, әгәр бу акча берәүнең намус белән эшләп алган хезмәт хакы булса, аның өендә сабыйлары көтеп утырса...

16) Шамил сумкасыннан кәгазь кисәге чыгарып, нәрсәдер язды да белдерүләр тактасына ябыштырып куйды. 17) Анда: “ Акча таптым, иясе килеп алсын, адресым менә шулай...” дип язылган иде.

18) Шамил кайтып кергәндә, әнисе өйдә иде инде, озакламый әтисе дә кайтты.

19) – Мин акча таптым!- диде малай, сумкасын диванга ташлап.

20) Әтисе, эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, хәзер үк акчаны милиция бүлеге каршындагы табылдыклар өстәленә илтеп тапшырырга кирәклеген әйтте.

21) – Юк , әти, иясе хәзер килеп җитәр,- диде Шамил. 22) – Мин, адресны күрсәтеп, белдерү ябыштырдым.

23) Моны ишеткәч, әти-әнисенең күңелләре булды, улларының табылган акчаны иясенә тапшыру чарасына керешүен күреп куандылар.

24) Кич булды, шул вакыт өйгә уртача яшьләрдәге бер хатын килеп керде.

25) – Сез акча тапкансыз, минеке түгел микән ул? – диде хатын.

26) – Әйе, менә мәктәптә укучы малаем тапкан, - дип, әти кулъяулыкка төрелгән акчаларны чыгарды. 27) Шунда хатын аптырап калды һәм акчаларының мондый кулъяулыкка төрелмәгәнлеген әйтте.

28) – Бу минем акчалар түгел, - дип, ишеккә юнәлде.

29) Шунда малайның әтисе аны туктатып:

- Намуслы хатын икәнсез, мин сезне сынар өчен аны үз яулыгыма төргән идем, - дип, куеныннан зәңгәр читле яулыкны чыгарды.

30) Хатын, акчаларны алып, малайга рәхмәтләр укый-укый, өенә кайтып китте.

31) Хатын чыгып киткәч, әнисе улын кысып үпте дә йокларга кушты. 32) Шунда Шамил:

- Әнием, әйтергә онытканмын икән әле: мин бүген ике бишле алдым!- диде.

33) – Анысы да әйбәт, - диде әтисе, - ә менә бүгенге эшең барыннан да кыйммәтлерәк.

( Г. Бакировтан *)

*Госман Бакиров ( Госман Фәтхулла улы Бакиров) (1886 – 1982) – язучы, “ Беренче җиңү”, “ Яшәсен яшьләр”, “Безнең рапорт”, “Сафа балалары” дигән сәхнә әсәрләре, “Урак өсте” дигән хикәяләр җыентыгы, “Партизан малай”, “Классташлар”, “Укытучым”, әсәрләре, “Мыеклы бикә”, “Кадерле бүләк” кебек мәктәпкәчә яшьтәге балаларга адресланган китаплары бар.

.

**2-10 нчы биремнәрнең җавапларын сүз (сүзтезмә) яки цифр белән күрсәтегез.**

**2. Ирен гармониясенә** буйсынган сүзләр кулланылган җөмләне күрсәтегез.

1) Алар, Шамилнең бүген нинди билгеләр алып кайтуы турында сораша-сораша, гөрләшеп чәй эчеп утырырлар.

2) Хатын чыгып киткәч, әнисе улын кысып үпте дә йокларга кушты.

3) Шамил кайтып кергәндә, әнисе өйдә иде инде, озакламый әтисе дә кайтты.

4) Тукта, әгәр бу акча берәүнең намус белән эшләп алган хезмәт хакы булса, аның өендә сабыйлары көтеп утырса...

**3.** Сөйләмнең сәнгатьлелеген арттыру максатыннан, **фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез.

1) Кич булды, шул вакыт өйгә уртача яшьләрдәге бер хатын килеп керде.

2) Моны ишеткәч, әти-әнисенең күңелләре булды, улларының табылган акчаны иясенә тапшыру чарасына керешүен күреп куандылар.

3) – Сез акча тапкансыз, минеке түгел микән ул? – диде хатын.
4) ) Шамил чыгып китәм дигәндә генә, аягы ниндидер бер йомшак төенгә кагылып китте.

**4.** 29-33 нче җөмләләрдән **чагыштыру дәрәҗәсендәге асыл сыйфатны** күчереп языгыз.

**5.** 8-12 нче җөмләләрдән **каршы куючы теркәгечне** табып языгыз.

**6.** 1 нче абзацтан *каты* сүзенең **антонимын** табып языгыз.

**7.** 30 нчы җөмләнең **грамматик нигезен** күчереп языгыз.

**8.** 1-5 нче җөмләләрдән **иярченле кушма җөмләнең** номерын языгыз.

**9.** Җөмләдә барлык тыныш билгеләре номерланган. **Тезүле бәйләнештәге җөмләләр** арасына куелган **тыныш билгесенең номерын** языгыз.

- (1) Намуслы хатын икәнсез, (2)мин,(3) сезне сынар өчен, (4) аны үз яулыгыма төргән идем,(5) – (6) дип, (7) куеныннан зәңгәр читле яулыкны чыгарды.(8)

**10.** Сөйләмнең тәэсир итү көчен арттыру өчен, 4-7 нче җөмләләр арасыннан **кире сүз тәртибе** файдаланылган җөмләнең номерын языгыз.

## 3 нче бүлек

**2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 11.1, 11.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып үтәгез. Яза башлар алдыннан, сайланган биремнең номерын күрсәтегез.**

**11.1. « Шамил: “ Әнием, әйтергә оныткамын икән әле: мин бүген ике бишле алдым!- диде. “ Анысы да әйбәт, - диде әтисе, - ә менә бүгенге эшең барыннан да кыйммәтлерәк”** җөмләләрендә әйтелгән фикерне сез ничек аңлыйсыз?

Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш. Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый. Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен, ноль балл куела.

**11.2 “Намус җаннан кадерле ”** мәкале бар халыкта. Аның мәгънәсен ничек аңлыйсыз? **Намус** төшенчәсенә аңлатма бирегез. **“ Пычак ярасы китә, намус карасы китми”** темасына сочинение языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан –

**1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениене мәкаль һәм әйтемнән башлый аласыз. Аны фәнни яки публицистик стильдә язарга мөмкин.

Сочинениенең күләме 50 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган тестка таянып язылмаган эшкә билге куелмый. Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен , билге куелмый.( ноль балл куела)

## III вариант

### Эш башкару өчен күрсәтмә

Татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныфын тәмамлаучыларга татар теленнән бердәм республика тестын үтәү өчен, 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә. Тест биремнәре 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек** 1 биремнән гыйбарәт. 2 тапкыр тыңланган текстның кыскача эчтәлеге (изложение) 2 нче номерлы бланкка языла.

**Икенче бүлек** укучылар үзләре укыган текст нигезендә эшләнелә. Ул 9 биремнән (2-10) тора.

2 – 3 нче биремнәрне үтәгәндә, дөрес җавапны тәкъдим ителгән 4 варианттан сайлап алып, 1 нче номерлы җавап бланкына 1 цифр белән язарга кирәк.

4-10 нчы биремнәргә җавапларны мөстәкыйль рәвештә формалаштырасыз. Әлеге биремнәргә җаваплар сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән 1 нче номерлы җавап бланкына языла. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга кирәк.

**Өченче бүлектәге биремнәрне** эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән ике биремнең (11.1 яки 11.2) берсен генә сайлап алыгыз һәм дәлилле киңәйтелгән җавап языгыз. Әлеге бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Бердәм республика тесты материалларының барлык бүлекләрендәге биремнәрне үтәгәндә, орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне үтәгәндә, карамаладан файдаланырга ярый. **Шуны истә тотыгыз**: карамаладагы язмаларыгыз эшне бәяләгәндә исәпкә алынмаячак.

Биремнәрне эзлекле рәвештә башкару тәкъдим ителә.

Балларны бергә кушканнан соң, гомуми балл чыгарыла. Шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

### 1 нче бүлек

| |
|---|
| **Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне эшләгез.**<br>**Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.** |

**1.Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.**

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложение күләме **50 сүздән** ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

### 2 нче бүлек

| |
|---|
| **Текстны укыгыз һәм 2-10 нчы биремнәрне үтәгез.** |

### Автобустагы исем

1)Таҗиларның авылы тау өстендә. 2)Авылның елга аръягында шикәр заводы салалар. Авыл белән ике арада, эшчеләрне ташып, автобуслар йөри. 4) Таҗи көн дә мәктәптән кайта да, аннан-моннан гына капкалап, автобуслар йөри торган чатка йөгерә. 5) Автобуслар килә-китә тора, ләкин Таҗи аларга карамый да. 6) Ул ишек пыяласы чатнаган автобусны көтә. 7) Аның да гел бер урындыгына утыра. 8) Утырмас иде дә- сере бар.

9) Менә бүген дә иялә шкән машинасы килеп туктауга, Таҗи ялт итеп үз урындыгына менеп утырды.

10)Бераз баргач, автобуска бала күтәргән бер апа керде. 11) Ул кешеләргә күз йөртеп чыкты, урын тапмагач, басып бара башлады.12) Таҗи аны күрүгә сикереп торды.

13) –Минә монда утырыгыз, апа, минем урынга,-диде.

14) Апа утырды һәм, елмаеп, Таҗига рәхмәт әйтте.

15) Таҗиның күзләре гел шул апада булды- күрерме, юкмы?! 16) Ләкин апа алдагы утыргычның алдына карамады. 17) Югыйсә бер чакрымнан аермачык булып күренеп тора бит инде! 18) “Т” хәрефе бар, “А”, аннан соң “Җ” белән “И”. 19) Дүртесен бергә кушсаң, Таҗиның исеме килеп чыга. 20) Ул аны үзе язды, урындык калаеның ак буявын очлы кадак белән тырный-тырный арып бетте. 21) Аруы бушка китмәде, әнә ничек матур язылган. 22) Таҗи урындык аркасындагы шул исемне- үз исемен кайчан да булса берәр кеше күрер әле дип уйлый. 23) Күргәч, кара, бездә Таҗи исемле егет бар икән, беләсе иде, кем икән ул, дияр. 24) Таҗи үзе шул чакта читтән генә карап торыр. 25) Теге кешеләр Таҗиның үз яннарында гына баруын исләренә дә алмыйча төшеп китәрләр. 26) Ә исем шулай бик озак йөрер дә йөрер, бу авылда Таҗи исемле егет яшәвен әкренләп бөтен кеше дә белер.

27) Таҗи шуларны уйлады, апаның язуны күрүен теләде. 28) Тора торгач, теләге кабул булды бит: апа алдагы утыргыч артына күз салды. 29) Аның кашлары җыерылды, йөзенә ачулы төс керде.

30) –Та-җи! 31) Һм, тапкан язар җир,- дип сөйләнеп куйды ул. 32) – Буяуны кырган, калайны сыдырган, нинди матур автобусның ямен җибәргән, әшәке малай икән бу Таҗи...

33) Аннан соң ул алдындагы бәләкәй улын тагын да җайлабрак утыртып куйды.

34) – Ә син, бәбкәм, ул әшәке малай шикелле булмассың, син безгә урын биргән менә бу әйбәт абыең кебек булырсың. 35) Әнә ул нинди акыллы, бите-кулы чиста, киемнәре пөхтә.

36) Апа шулай диде дә, елмаеп, Таҗига карады. 37) Ләкин елмаймаса, ун кат, мең кат яхшырак буласы икән. 38) Таҗи эсселе-суыклы булып китте. 39) Ул беренче тукталышта ук автобустан шыпырт кына төшеп калды.

(Г.Мөхәммәтшиннан*)

*Газиз Мөхәммәтшин (Газиз Фазлый улы Мөхәммәтшин) (1932-1972) – татар язучысы, драматургы. Әдипнең “Бал чүлмәге”, “Без ничек ураза тоттык”, “Дулкыннар”, “Ике әби бәрәңге ала” әсәрләре укучыларга яхшы таныш.

**2-10 нчы биремнәрнең җавапларын сүз (сүзтезмә) яки цифр белән күрсәтегез.**

**2. Ирен гармониясенә буйсынган сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез.**

1) Авыл белән ике арада, эшчеләрне ташып, автобуслар йөри.

2) Таҗи көн дә мәктәптән кайта да, аннан-моннан гына капкалап, автобуслар йөри торган чатка йөгерә.

3) Таҗи шуларны уйлады, апаның язуны күрүен теләде.

4) Буяуны кырган, калайны сыдырган, нинди матур автобусның ямен җибәргән, әшәке малай икән бу Таҗи...

**3.** Сөйләмнең сәнгатьлелеген арттыру максатыннан, **фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез.

1) Ул аны үзе язды, урындык калаеның ак буявын очлы кадак белән тырный-тырный арып бетте.

2) Аннан соң ул алдындагы бәләкәй улын тагын да җайлабрак утыртып куйды.

3) Ул беренче тукталышта ук автобустан шыпырт кына төшеп калды.

4) Тора торгач, теләге кабул булды бит: апа алдагы утыргыч артына күз салды.

**4.** 23-25 нче җөмләләрдән **төшем килешендәге исем фигыльне** күчереп языгыз.
**5.** 1- 8 нче җөмләләр арасыннан баш килешне таләп итүче бәйлекне табып языгыз.
**6.** 33-35 нче җөмләләр арасыннан *антонимнар булган җөмләнең номерын* языгыз.
**7.** 1 нче җөмләнең грамматик нигезен күчереп языгыз.
**8.** 5-8 нче җөмләләр арасыннан **иярченле кушма җөмләнең** номерын языгыз.
**9.** Аерымланган хәлдән соң куелган тыныш билгесенең номерын языгыз.
Күргәч, (1) кара, (2) бездә Таҗи исемле егет бар икән, (3) беләсе иде, (4) кем икән ул, (5) дияр. (6)
**10.** Сөйләмнең тәэсир итү көчен арттыру өчен, 27-31 нче җөмләләр арасыннан **кире сүз тәртибе** файдаланылган җөмләнең номерын языгыз.

## 3 нче бүлек

**2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 11.1, 11.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып үтәгез. Яза башлар алдыннан, сайланган биремнең номерын күрсәтегез.**

**11.1. «Таҗи эсселе-суыклы булып китте. Ул беренче тукталышта ук автобустан шыпырт кына төшеп калды »** җөмләләрендә әйтелгән фикерне сез ничек аңлыйсыз?
Фикерегезне раслау өчен, укылган текстан **2 мисал** китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки текстан цитата китерегез.
Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш.
Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.
Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.
Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен, ноль балл куела.

**11.2. “Хатаңны әйтүчене атаң дип бел”,** - дигән мәкаль бар халыкта. Аның мәгънәсен ничек аңлыйсыз? **“Хата”** төшенчәсенә аңлатма бирегез. Сезнеңчә, Таҗиның хатасы нәрсәдә? **“Хатаңны әйтүчене атаң дип бел”** темасына сочинение языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган текстан – **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.
Сочинениенең күләме **50** сүздән дә ким булмаска тиеш.
Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.
Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.
Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен, ноль балл куела.

## IV вариант

### Эш башкару өчен күрсәтмә

Татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныфын тәмамлаучыларга татар теленнән бердәм республика тестын үтәү өчен, 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә. Тест биремнәре 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек** 1 биремнән гыйбарәт. 2 тапкыр тыңланган текстның кыскача эчтәлеге (изложение) 2 нче номерлы бланкка языла.

**Икенче бүлек** укучылар үзләре укыган текст нигезендә эшләнелә. Ул 9 биремнән (2-10) тора.

2 – 3 нче биремнәрне үтәгәндә, дөрес җавапны тәкъдим ителгән 4 варианттан сайлап алып, 1 нче номерлы җавап бланкына 1 цифр белән язарга кирәк.

4-10 нчы биремнәргә җавапларны мөстәкыйль рәвештә формалаштырасыз. Әлеге биремнәргә җаваплар сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән 1 нче номерлы җавап бланкына языла. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга кирәк.

**Өченче бүлектәге биремнәрне** эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән ике биремнең (11.1 яки 11.2) берсен генә сайлап алыгыз һәм дәлилле киңәйтелгән җавап язгыгыз. Әлеге бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Бердәм республика тесты материалларының барлык бүлекләрендәге биремнәрне үтәгәндә, орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне үтәгәндә, карамаладан файдаланырга ярый. **Шуны истә тотыгыз**: карамаладагы язмаларыгыз эшне бәяләгәндә исәпкә алынмаячак.

Биремнәрне эзлекле рәвештә башкару тәкъдим ителә.

Балларны бергә кушканнан соң, гомуми балл чыгарыла. Шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

## 1 нче бүлек

| **Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне эшләгез.<br>Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.** |
|---|

**1.Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.**

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложение күләме **50 сүздән** ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## 2 нче бүлек

| **Текстны укыгыз һәм 2-10 нчы биремнәрне үтәгез.** |
|---|

### Әманәт

1)Ни хикмәттер, элекке кебек, каз суйган көннәрдә, шау-гөр килеп, каз өмәләре ясаулар бетте. 2)Әллә авыр сугыш елларында ачлы-туклы яшәгән чакларда өзелде бу гадәт, әллә инде дөнья куарга бирелгән кешеләрнең бер дә юктан тагын бер бәйрәм ясап, вакыт әрәм итәселәре килми. 3)Бәйрәмнәр болай да җитәрлек бит.

4)Борын-борыннан килгән бу гадәтне түбән очның Майшәкәр апа гына онытып бетерми иде. 5)Каз суйган вакытларга туры китереп, күрше-күләндәге балаларны кунакка чакыра. 6)Күңеле тыныч булсын Габделхәемнең, васыятен үтим, дип, исәнлектә кадер-хөрмәт күрсәтеп өлгерә алмаган якын кешесенә аз булса да яхшылык итүенә сөенеп эшли ул аны.

7) Бервакыт шулай ел да үрчетә торган сигез-ун баш казын берүзе эш итеп куйгач, ике-өч көнгә сузылган ялыктыргыч бу эштән тәмам туеп, шулай да келәт киштәсендәге симез каз түшкәләренә куанып, мамыктан тузгыган өен көч-хәл белән җыеп чыккач, арып-талып, урынына менеп ятты. 8)Ничә еллар төшенә кергәне юк иде, бу төндә ул Габделхәе белән күреште. 9)Төсен-битен яхшылап хәтерләми, ә менә тавышы уянгач та колак төбендә яңгырап тора иде әле:

-Балаларны ашаттыңмы?

10)Нигә шулай дип әйтте икән? 11)Онытып бетердең, дип үпкәләвеме әллә? 12)Майшәкәр апа төшен ни дип юрарга да белмәде. 13)Икенче көнне ул, мәрхүмнең рухы тыныч булсын дип, сабыйларны җыеп кунак итте. 14)Аннан соң алдагы елларда да шулай эшләде. 15) Һаман бер вакытта үткәрелгән бу бәйрәмгә инде балалар да күнегеп бетте.

(Л.Ихсановадан)*

***Ләбибә Ихсанова** (Ләбибә Фәез кызы Ихсанова) –күренекле балалар язучысы, күпсанлы шигырь, хикәя һәм повестьлар, тәнкыйть мәкаләләре авторы, оста тәрҗемәче. “Көмеш елга”, “Гөлләр кояшка карый”, Милиционер малае”, “Якты уйлар” кебек әсәрләре укучылар күңеленә гуманистик идеяләр сеңдерә.

**2-10 биремнәрнең җавапларын сүз(сүзтезмә) яки цифр белән күрсәтегез.**

**2.Борын ассимиляциясе** күзәтелгән сүз булган җөмләне күрсәтегез.

1)Ничә еллар төшенә кергәне юк иде, бу төндә ул Габделхәе белән күреште.
2) Бәйрәмнәр болай да җитәрлек бит.
3) Һаман бер вакытта үткәрелгән бу бәйрәмгә инде балалар да күнегеп бетте.
4) Каз суйган вакытларга туры китереп, күрше-күләндәге балаларны кунакка чакыра.

3.Сөйләмнең сәнгатьлелеген арттыру максатыннан, **фразеологик әйтелмә** кулланылган җөмләне күрсәтегез.

1) Әллә авыр сугыш елларында ачлы-туклы яшәгән чакларда өзелде бу гадәт, әллә инде дөнья куарга бирелгән кешеләрнең бер дә юктан тагын бер бәйрәм ясап, вакыт әрәм итәселәре килми.
2) Борын-борыннан килгән бу гадәтне түбән очның Майшәкәр апа гына онытып бетерми иде.
3) Ни хикмәттер, элекке кебек, каз суйган көннәрдә, шау-гөр килеп, каз өмәләре ясаулар бетте.
4) Ничә еллар төшенә кергәне юк иде, бу төндә ул Габделхәе белән күреште.

4. 4-6 нчы җөмләләрдән **күләм-чама рәвешен** табып языгыз.

5. 1-4 нче җөмләләрдән **раслаучы кисәкчәне** табып языгыз.

6. 2 нче җөмләдән <u>*җиңел*</u> сүзенең **антонимын** табып языгыз.

7. 1 нче җөмләдән **грамматик нигезне** күчереп языгыз.

8. 12-25 нче җөмләләрдән **иярченле кушма җөмләнең** номерын языгыз.

9. Тезүле бәйләнештәге җөмләләр арасына куелган **тыныш билгесенең номерын** языгыз.

*Әллә авыр сугыш елларында ачлы-туклы яшәгән чакларда өзелде бу гадәт,(1) әллә инде дөнья куарга бирелгән кешеләрнең бер дә юктан тагын бер бәйрәм ясап, (2) вакыт әрәм итәселәре килми. (3)*

10. Стилистик максатлардан чыгып, 4-6 нчы җөмләләр арасыннан **кире сүз тәртибе** күзәтелгән җөмләне табыгыз.

**3 нче бүлек**

**2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 11.1, 11.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып үтәгез. Яза башлар алдыннан, сайланган биремнең номерын күрсәтегез.**

11.1. **“Борын-борыннан килгән бу гадәтне түбән очның Майшәкәр апа гына онытып бетерми иде. Каз суйган вакытларга туры китереп, күрше-күләндәге балаларны кунакка чакыра”** җөмләләрендә әйтелгән фикерне сез ничек аңлыйсыз?

Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме 50 сүздән дә ким булмаска тиеш. Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый. Бирелгән текстны күчереп яисә аның фикерегезне раслау өчен эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен, ноль балл куела.

11.2. **“Җаның олы булса, һәр эшең олы**”,- диелә халык мәкалендә. Бу мәкальнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? Сезнеңчә, Майшәкәр апаны олы җанлы дип буламы? Ни өчен? **“Җаның олы булса, һәр эшең олы” темасына сочинение языгыз.** Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **-1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** ким булмаска тиеш. Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый. Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен, ноль балл куела.